**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О Комиссии при Президенте Республики Татарстан по русскому языку

В целях организации взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан с федеральными органами исполнительной власти, их территориальными органами, органами местного самоуправления, общественными объединениями по вопросам содействия реализации государственной политики в области функционирования русского языка, в соответствии со статьей 94 Конституции Республики Татарстан **постановляю**:

1. Образовать Комиссию при Президенте Республики Татарстан по русскому языку.

2. Утвердить Положение о Комиссии при Президенте Республики Татарстан по русскому языку (приложение № 1) и ее состав (приложение № 2).

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
20 мая 2022 года
№ УП-355

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «20» мая 2022 года

№ УП-355

**Положение**
**о Комиссии при Президенте Республики Татарстан по русскому языку**

1. Комиссия при Президенте Республики Татарстан по русскому языку (далее – Комиссия) является постоянно действующим консультативным органом, созданным в целях выработки мер по содействию реализации государственной политики в области функционирования русского языка.

2. Положение о Комиссии и ее состав утверждаются Указом Президента Республики Татарстан.

3. Комиссия в своей деятельности руководствуется Конституцией Российской Федерации, федеральными конституционными законами, Федеральным законом от 1 июня 2005 года № 53-ФЗ «О государственном языке Российской Федерации», другими федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, Законом Республики Татарстан от 8 июля 1992 года № 1560-XII «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан», другими законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан, а также настоящим Положением.

4. Основными задачами Комиссии являются:

организация взаимодействия органов государственной власти Республики Татарстан и местного самоуправления с федеральными органами исполнительной власти, их территориальными органами, общественными объединениями по вопросам функционирования русского языка;

определение актуальных вопросов, связанных с функционированием русского языка и выработка возможных подходов к их решению;

изучение и обобщение лучших практик, методик и технологий изучения русского языка, повышения культуры речи и определение мер по их распространению;

инициирование мер поддержки перспективных направлений и проектов, связанных с функционированием русского литературного языка, а также изучением и сохранением устного народного творчества;

поддержка инициатив, творческих начинаний, направленных на повышение культуры речи, в том числе представляющих особый интерес для детей и молодежи;

участие в экспертной оценке законодательных инициатив;

обеспечение выработки мер по использованию русского языка во взаимосвязи с другими языками, развитию билингвального и полилингвального образования;

принятие мер по повышению уровня подготовки специалистов, деятельность которых связана с профессиональным использованием русского языка;

содействие популяризации знаний о русском языке.

5. Комиссия для решения возложенных на нее задач имеет право:

запрашивать в установленном законодательством порядке от органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти по Республике Татарстан (далее – территориальные органы федеральных органов исполнительной власти), иных государственных органов, органов местного самоуправления муниципальных образований Республики Татарстан (далее – органы местного самоуправления), а также общественных объединений, научных и иных организаций материалы и информацию по вопросам, относящимся к компетенции Комиссии;

приглашать на свои заседания представителей органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, иных государственных органов, органов местного самоуправления, а также общественных объединений, научных и иных организаций;

вносить в установленном порядке в органы государственной власти Республики Татарстан, территориальные органы федеральных органов исполнительной власти, иные государственные органы, органы местного самоуправления предложения по вопросам, относящимся к компетенции Комиссии;

создавать при необходимости рабочие и экспертные группы из числа ученых и специалистов для подготовки предложений по решению вопросов популяризации, поддержки и развития русского языка.

6. Состав Комиссии формируется из представителей органов государственной власти Республики Татарстан, территориальных органов федеральных органов исполнительной власти, иных государственных органов, органов местного самоуправления, общественных объединений, научных и иных организаций, а также представителей экспертного сообщества. В состав Комиссии при необходимости могут включаться иные лица.

7. В состав Комиссии входят председатель, заместитель председателя, секретарь и члены Комиссии, осуществляющие свою деятельность на общественных началах.

8. Руководит работой Комиссии и проводит ее заседания председатель Комиссии, а в его отсутствие – заместитель председателя Комиссии.

9. Секретарь Комиссии:

готовит проект плана работы Комиссии, формирует повестку дня заседания Комиссии с учетом предложений членов Комиссии;

осуществляет информирование членов Комиссии и иных заинтересованных лиц о месте, времени проведения и повестке дня заседания Комиссии, обеспечивает их необходимыми материалами;

организует работу по подготовке заседаний Комиссии;

ведет протоколы заседаний Комиссии;

осуществляет контроль за выполнением решений Комиссии.

В случае отсутствия секретаря его обязанности по решению председателя Комиссии возлагаются на одного из членов Комиссии.

10. Комиссия осуществляет свою деятельность в соответствии с планом работы, утверждаемым председателем Комиссии.

Члены Комиссии вносят предложения по плану работы, повестке дня заседания и участвуют в подготовке материалов к заседанию Комиссии.

11. Заседания Комиссии проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в год.

12. Заседание Комиссии считается правомочным, если в нем принимают участие более половины ее членов.

13. В случае отсутствия члена Комиссии на заседании он имеет право изложить в письменной форме свое мнение по рассматриваемым вопросам, которое подлежит обязательному приобщению к протоколу заседания Комиссии.

14. Решения Комиссии принимаются простым большинством голосов. При равенстве голосов членов Комиссии голос председательствующего на заседании является решающим.

15. Решение Комиссии оформляется протоколом, который подписывается секретарем Комиссии и утверждается председательствующим на заседании Комиссии.

16. Организационное и информационное обеспечение деятельности Комиссии осуществляется Аппаратом Кабинета Министров Республики Татарстан.

---

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «20» мая 2022 года

№ УП-355

**Состав**
**Комиссии при Президенте Республики Татарстан по русскому языку**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Премьер-министр Республики Татарстан, председатель Комиссии |
| Камалтынов Юрий Зимелевич | заместитель Председателя Государственного Совета Республики Татарстан, заместитель председателя Комиссии (по согласованию) |
| Фазлеева Лейла Ринатовна | заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, заместитель председателя Комиссии |
| Александровская Ирина Алексеевна | председатель правления региональной общественной организации «Русское национально-культурное объединение Республики Татарстан», директор муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Гимназия № 93» Советского района г. Казани, заместитель председателя Комиссии (по согласованию) |
| Выборнов Андрей Андреевич | начальник отдела высшего, среднего профессионального образования и науки Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан, секретарь Комиссии |
| Адгамова Юлия Ильдаровна | первый заместитель министра культуры Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Бушканец Лия Ефимовна | заведующий кафедрой иностранных языков в сфере международных отношений Высшей школы иностранных языков и перевода Института международных отношений федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет», член Чеховской комиссии Совета по истории мировой культуры Российской академии наук (по согласованию) |
| Гущина Елена Геннадьевна | исполняющий обязанности заведующего кафедрой антропологии и этнографии Высшей школы исторических наук и всемирного культурного наследия Института международных отношений федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |
| Демидов Сергей Анатольевич | глава муниципального образования «Алексеевский муниципальный район» (по согласованию) |
| Елистратова Галина Николаевна | директор государственного бюджетного учреждения «Культурный центр имени А.С. Пушкина» (по согласованию) |
| Ерофеева Ирина Валерьевна | профессор кафедры русского языка и методики его преподавания Высшей школы русского языка и межкультурной коммуникации им. И.А. Бодуэна де Куртенэ Института филологии и межкультурной коммуникации федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет», руководитель Экспертного совета преподавателей и учителей русского языка города Казани Международной просветительской акции «Тотальный диктант» по русскому языку в Республике Татарстан (по согласованию) |
| Завьялова Ирина Васильевна | заведующий музеем Е.А. Боратынского – филиалом государственного бюджетного учреждения культуры «Национальный музей Республики Татарстан» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Зайцев Артем Юрьевич | руководитель молодежной музыкально-поэтической арт-группы «Живаго» (по согласованию) |
| Залялова Анфиса Григорьевна | директор государственного автономного профессионального образовательного учреждения «Казанский педагогический колледж», председатель некоммерческого партнерства «Совет директоров образовательных учреждений среднего профессионального образования Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Замалетдинов Радиф Рифкатович | директор Института филологии и межкультурной коммуникации федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет», член Совета при Президенте Российской Федерации по русскому языку (по согласованию) |
| Иванов Дмитрий Алексеевич | глава муниципального образования «Чистопольский муниципальный район» (по согласованию) |
| Кондратьева Алла Андреевна | заместитель министра по делам молодежи Республики Татарстан |
| Куракина Татьяна Сергеевна | исполнительный директор частного общеобразовательного учреждения религиозной организации «Казанская Епархия Русской Православной Церкви (Московский Патриархат)» «Православная гимназия имени святителя Гурия Казанского г. Казани» (по согласованию) |
| Лодвигова Евгения Анатольевна | заместитель главы муниципального образования города Казани (по согласованию) |
| Мерзон Елена Ефимовна | директор Елабужского института (филиала) федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |
| Низамова Ляйсан Гаптелхановна | начальник Управления культуры и развития языков народов Республики Татарстан Аппарата Кабинета Министров Республики Татарстан |

| | |
|---|---|
| Нугуманова Людмила Николаевна | ректор государственного автономного образовательного учреждения дополнительного профессионального образования «Институт развития образования Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Пашкуров Алексей Николаевич | профессор кафедры русской литературы и методики ее преподавания Высшей школы русского языка и межкультурной коммуникации им. И.А. Бодуэна де Куртенэ Института филологии и межкультурной коммуникации федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |
| Первакова Светлана Владимировна | заведующая Центром русского фольклора муниципального бюджетного учреждения культуры города Казани «Музейный комплекс города Казани» (по согласованию) |
| Редько Зоя Васильевна | директор муниципального автономного общеобразовательного учреждения города Набережные Челны «Лицей № 78 им. А.С. Пушкина» (по согласованию) |
| Рыбакова Людмила Николаевна | заместитель председателя Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по образованию, культуре, науке и национальным вопросам (по согласованию) |
| Сороковнина Елена Владимировна | заместитель руководителя Исполнительного комитета муниципального образования «Камско-Устьинский муниципальный район», председатель Камско-Устьинского отделения региональной общественной организации «Русское национально-культурное объединение Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Сушенцова Татьяна Ивановна | председатель Татарстанского республиканского отделения общероссийской общественной организации «Союз писателей России» (по согласованию) |

| | |
|---|---|
| Терентьев Александр Михайлович | заместитель Руководителя Аппарата Президента Республики Татарстан – руководитель Департамента Президента Республики Татарстан по вопросам внутренней политики |
| Титова Татьяна Алексеевна | профессор кафедры антропологии и этнографии Высшей школы исторических наук и всемирного культурного наследия Института международных отношений федерального государственного автономного образовательного учреждения высшего образования «Казанский (Приволжский) федеральный университет» (по согласованию) |
| Федорова Тамара Трофимовна | директор учреждения профессионального образования «Колледж «ТИСБИ» (по согласованию) |
| Хадиуллин Ильсур Гараевич | министр образования и науки Республики Татарстан |
| Шагаева Алия Юнусовна | директор муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Лицей № 9 имени А.С. Пушкина Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан» (по согласованию) |
| Шаталов Вячеслав Владимирович | директор региональной молодежной общественной организации «Центр культур и диалога» Республики Татарстан, координатор Международной просветительской акции «Тотальный диктант» по русскому языку в Республике Татарстан (по согласованию) |
| Юдин Владислав Павлович | директор государственного автономного учреждения культуры Республики Татарстан «Бугульминский государственный русский драматический театр имени А.В. Баталова» (по согласованию) |
| Яковлев Константин Геннадиевич | заместитель председателя Совета региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан» – руководитель Исполнительного комитета Совета региональной общественной организации «Ассамблея представителей народов, проживающих на территории Республики Татарстан» (по согласованию) |

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясе турында**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр белән рус теленең кулланылышы өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлеген оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясен төзергә.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясе турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 20 май
№ ПУ-355

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 20 » маендагы
ПУ-355 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы
рус теле комиссиясе турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы рус теле комиссиясе (алга таба – Комиссия) рус теленең кулланылышы өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга ярдәм күрсәтү чараларын эшләү максатларында төзелгән даими эшләүче консультация органы булып тора.

2. Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә раслана.

3. Комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, «Россия Федерациясенең дәүләт теле турында» 2005 елның 1 июнендәге 53-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасының башка законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.

4. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының федераль башкарма хакимият органнары, аларның территориаль органнары, иҗтимагый берләшмәләр белән рус теленең кулланылышына кагылышлы мәсьәләләр буенча үзара хезмәттәшлеген оештыру;

рус теленең кулланылышы белән бәйле актуаль мәсьәләләрне билгеләү һәм аларны хәл итүнең мөмкин булган ысулларын эшләү;

рус телен өйрәтүнең, сөйләм культурасын үстерүнең иң яхшы тәҗрибәләрен, методикаларын һәм технологияләрен өйрәнү һәм гомумиләштерү һәм аларны тарату чараларын билгеләү;

рус әдәби теленең кулланылышы, шулай ук халык авыз иҗатын өйрәнү һәм саклау белән бәйле перспективалы юнәлешләргә һәм проектларга ярдәм күрсәтү башлангычлары белән чыгу;

сөйләм культурасын үстерүгә юнәлтелгән, шул исәптән балалар һәм яшьләр өчен аеруча кызыксыну тудырачак эшчәнлеккә, иҗади башлангычларга булышлык итү;

законнар чыгару башлангычларына экспертлар бәяләмәсе әзерләүдә катнашу;

рус теленең башка телләр белән үзара бәйләнештә кулланылуын тәэмин итү, билингваль һәм полилингваль белем бирүне үстерү;

рус телен һөнәри куллану белән бәйле эшчәнлек алып баручы белгечләрнең әзерлек дәрәҗәсен яхшырту чараларын күрү;

рус теле турында белемнәрне популярлаштыруга булышлык итү.

5. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итүдә түбәндәгеләргә хокуклы:

законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан (алга таба – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары), башка дәүләт органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарыннан (алга таба – җирле үзидарә органнары), шулай ук җәмәгать берләшмәләреннән, фәнни һәм башка оешмалардан Комиссия компетенцияләренә караган мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук җәмәгать берләшмәләре, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләрен чакырырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр бирергә;

ихтыяҗ туганда, рус телен популярлаштыру, аңа булышлык күрсәтү һәм үстерү мәсьәләләрен хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү өчен галимнәр һәм белгечләрдән торган эш һәм эксперт төркемнәре төзергә.

6. Комиссия составы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләреннән, шулай ук эксперт берләшмәләре вәкилләреннән формалаштырыла. Комиссия составына, кирәк булган очракта, башка затлар да кертелергә мөмкин.

7. Комиссия составына рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм Комиссия әгъзалары керә, алар үз эшчәнлеген җәмәгать башлангычларында алып бара.

8. Комиссия эшенә Комиссия рәисе, ул булмаганда – Комиссия рәисе урынбасары җитәкчелек итә һәм аның утырышларын алып бара.

9. Комиссия секретаре:

Комиссиянең эш планы проектын әзерли, Комиссия әгъзалары тәкъдимнәрен исәпкә алып, Комиссия утырышының көн тәртибен төзи;

Комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга Комиссия утырышы булачак урын, аны уздыру вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Комиссия утырышларын әзерләү буенча эшне оештыра;

Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара;

Комиссия карарларының үтәлешен контрольдә тота.

Секретарь булмаганда, аның вазыйфалары Комиссия рәисе карары нигезендә Комиссия әгъзаларының берсенә йөкләнә.

10. Комиссия үз эшчәнлеген Комиссия рәисе тарафыннан расланган эш планы нигезендә алып бара.

Комиссия әгъзалары утырышның эш планына, көн тәртибенә кагылышлы тәкъдимнәр кертә һәм Комиссия утырышына материаллар әзерләүдә катнаша.

11. Комиссия утырышлары ихтыяҗ туган саен, ләкин ким дигәндә елга бер тапкыр үткәрелә.

12. Комиссия әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашкан очракта, Комиссия утырышы гамәлгә хокуклы дип санала.

13. Утырышта катнашмаган очракта, Комиссия әгъзасы карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язмача белдерергә хокуклы һәм ул мәҗбүри рәвештә утырыш беркетмәсенә теркәлергә тиеш.

14. Комиссия карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары саны тигез булган очракта, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

15. Комиссия карары Комиссия секретаре кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан раслана.

16. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм мәгълүмати тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан тормышка ашырыла.

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның « 20 » маендагы
ПУ- 355 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы**
**рус теле комиссиясе**
**составы**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Комиссия рәисе |
| Камалтынов Юрий Зимелевич | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары |
| Александровская Ирина Алексеевна | «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, Казан шәһәре Совет районының «93 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, Комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Выборнов Андрей Андреевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы, Комиссия секретаре |
| Әдһәмова Юлия Илдар кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |

| | |
|---|---|
| Бушканец Лия Ефимовна | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты Чит телләр һәм тәрҗемә югары мәктәбенең халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чит телләр кафедрасы мөдире, Россия фәннәр академиясе Дөнья мәдәнияте тарихы советының Чехов комиссиясе әгъзасы (килешү буенча) |
| Гущина Елена Геннадьевна | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбенең антропология һәм этнография кафедрасы мөдире вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Демидов Сергей Анатольевич | «Алексеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Елистратова Галина Николаевна | «А.С. Пушкин исемендәге мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Ерофеева Ирина Валерьевна | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты И.А. Бодуэн де Куртенэ исемендәге Рус теле һәм мәдәниятара багланышлар югары мәктәбенең рус теле һәм аны укыту методикасы кафедрасы профессоры, Татарстан Республикасында «Тоталь диктант» рус теле буенча халыкара мәгърифәти акциясенең Казан шәһәре рус теле мөгаллимнәре һәм укытучылары Эксперт советы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Завьялова Ирина Васильевна | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – Е.А. Боратынский музее мөдире (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зайцев<br>Артем Юрьевич | «Живаго» яшьләр музыкаль-шигърият арт-төркеме җитәкчесе (килешү буенча) |
| Җәләлова<br>Анфиса Григорьевна | «Казан педагогика көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры, «Татарстан Республикасының урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләре директорлар советы» коммерциячел булмаган партнерлыгы рәисе (килешү буенча) |
| Җамалетдинов<br>Рәдиф Рифкать улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, Россия Федерациясе Президенты каршындагы рус теле советы әгъзасы (килешү буенча) |
| Иванов<br>Дмитрий Алексеевич | «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Кондратьева<br>Алла Андреевна | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры урынбасары |
| Куракина<br>Татьяна Сергеевна | «Рус Православие Чиркәвенең (Мәскәү Патриархаты) Казан Епархиясе» дини оешмасының «Казан шәһәренең святитель Гурий Казанский исемендәге православие гимназиясе» гомуми белем бирү хосусый учреждениесе башкарма директоры (килешү буенча) |
| Лодвигова<br>Евгения Анатольевна | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары |
| Мерзон<br>Елена Ефимовна | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Алабуга институты (филиалы) директоры |
| Низамова<br>Ләйсән Габделхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Ногманова<br>Людмила Николаевна | «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Пашкуров<br>Алексей Николаевич | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты И.А. Бодуэн де Куртенэ исемендәге Рус теле һәм мәдәниятара багланышлар югары мәктәбенең рус әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Первакова<br>Светлана Владимировна | Казан шәһәренең «Казан шәһәре музей комплексы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең Рус фольклоры үзәге мөдире (килешү буенча) |
| Редько<br>Зоя Васильевна | Чаллы шәһәренең «А.С. Пушкин исемендәге 78 номерлы лицее» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Рыбакова<br>Людмила Николаевна | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сороковнина<br>Елена Владимировна | «Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасының Кама Тамагы бүлекчәсе рәисе (килешү буенча) |
| Сушенцова<br>Татьяна Ивановна | «Россия Язучылар берлеге» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика бүлекчәсе рәисе (килешү буенча) |
| Терентьев<br>Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Титова<br>Татьяна Алексеевна | «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институты Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбенең антропология һәм этнография кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Федорова<br>Тамара Трофимовна | «ТИСБИ» көллияте» һөнәри белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Һадиуллин<br>Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Шагаева<br>Алия Юныс кызы | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының А.С. Пушкин исемендәге 9 номерлы лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Шаталов<br>Вячеслав Владимирович | Татарстан Республикасының «Мәдәниятләр һәм багланышлар үзәге» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы директоры, Татарстан Республикасында «Тоталь диктант» рус теле буенча халыкара мәгърифәти акциясе координаторы (килешү буенча) |
| Юдин<br>Владислав Павлович | «А.В. Баталов исемендәге Бөгелмә дәүләт рус драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Яковлев<br>Константин Геннадиевич | «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |

———————